РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 3/10**

Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 17 апрелендәге 43/7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга - ярдәм алучыларның бердәм реестрын төзү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 08 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 17 апрелендәге 43/7 номерлы карарына кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

исемдә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

Карарның 1 нче кушымтасында:

исемендә, 1.1, 1.4, 2.4 пунктларында, «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов